КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 7 декабрь г.Казань № 1183

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр бирү тәртибен расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 7 декабрь, 1183 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының
җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 109-ТРЗ номерлы Закон) нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) тарафыннан дәүләт милке чикләнмәгән, муниципаль район составына керә торган шәһәр җирлекләре территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен бирү буенча тапшырылган Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен (төбәк яки муниципальара әһәмиятле автомобиль юлларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләрен бирү вәкаләтләреннән тыш) гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр (алга таба – субвенцияләр) бирү механизмы билгели.

2. Субвенцияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (алга таба – Министрлык) субвенцияләр белән баш эш итүче буларак билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Министрлык финанслар җиткерелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субвенцияне җирле үзидарә органына җибәрә.

4. Субвенция муниципаль берәмлекнең финанс органы өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган Татарстан Республикасы муниципаль районы бюджетының бердәм счетына күчерелә.

5. Җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары җирле үзидарә органнарына тапшырылган җирдән файдалану һәм җирлекне төзү кагыйдәләре расланган муниципаль районнар составына керә торган шәһәр, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап формасын раслау хакында» 2016 ел, 8 апрель, 200 нче карары белән расланган формада, 109-ТРЗ номерлы Законның 8 статьясында каралган срокларда бу

Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән, җирле үзидарә органнарына тапшырылган Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында Министрлыкка хисап кертә.

6. Җирле үзидарә органнары бирелә торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субвенцияләрнең максатчан файдаланылмавы өчен законнар нигезендә җавап бирә.

7. Агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата субвенцияләрнең файдаланылмый калган өлеше агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

8. Субвенцияләрдән максатчан файдаланылмаган, хисаплылык билгеләнгән срокта тапшырылмаган һәм (яки) җирле үзидарә органы тарафыннан Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган субвенцияләр бирү шартлары бозылган очракта, субвенция Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

9. Бу Тәртипнең 7 һәм 8 пунктларында күрсәтелгән субвенцияне кире кайтару сроклары бозылганда, җирле үзидарә органына карата әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар кулланыла.

10. Бу Тәртип нигезендә бирелгән субвенцияләрдән максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту 109-ТРЗ номерлы Законның 9 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.